**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында 2024 елны Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итү турында**

Татарстан Республикасында киләчәктә фән һәм технологияләрне үстерү, республиканың социаль-икътисадый үсешенең мөһим бурычларын хәл итүдә аларның ролен көчәйтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында 2024 елны Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Фәнни-технологик үсеш елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 14 сентябрь
№ 639